ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЕЛАБУГА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

19.04.2019

№ 8

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр советының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 елның 11 декабрендәге 1113 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр советының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2018 елның 13 декабрендәге 176 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетын (алга таба – Шәһәр бюджеты) үтәүгә кабул итәргә.

2. Шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Шәһәр бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү буенча бурычларны киметү чараларын күрергә;

квартал саен керемнәрнең ай саен керү фаразларын тәкъдим итәргә;

квартал саен керемнәр өлешендә Шәһәр бюджеты үтәлешенә анализ ясарга, фаразланган керемнәр буенча бюджетның фактик үтәлешендәге тайпылышларның сәбәпләрен күрсәтеп.

3. Билгеләргә:

а) 2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субвенцияләр, субсидияләр, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән бюджетара трансфертларның калган өлешләре Татарстан Республикасы бюджетына 2019 елның беренче 15 эш көне эчендә кире кайтарылырга тиеш;

б) 2018 елда файдаланылмаган бюджетара трансфертларга әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән ихтыяҗның булуы (булмавы) турында Шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан карар кабул итү, шулай ук алар тарафыннан үзләренә карата 2019 елда шул ук максатларга юнәлдерү өчен ихтыяҗ булуы турында карар кабул ителгән әлеге бюджетара трансфертларны Шәһәр бюджетына кире кайтару бюджет акчаларының баш администраторы билгеләгән тәртиптә формалаштырылган тиешле бюджет чыгымнары турында хисапны карау нәтиҗәләре буенча күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына күчкән көннән башлап 30 эш көне узганчы гамәлгә ашырыла;

в) әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән срокны үтәү максатларында, Шәһәр бюджеты керемнәренең бюджетара трансфертларны кире кайтарудан администрацияләүне гамәлгә ашыра торган баш администраторы әлеге пунктның

өченче абзацында каралган һәм 2018 елда максатчан билгеләнештәге субвенцияләр, субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән һәм файдаланылмаган бюджетара трансфертлар рәвешендәге калган бюджетара трансфертларны 2019 елда шул ук максатларга юнәлдерү ихтыяҗының булуы турында килештерү өчен Алабуга ш. Башкарма комитетыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрелгән карарларның күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча Татарстан Республикасы бюджетына килгән көннән башлап 10 эш көне эчендә каралуын тәэмин итә;

г) 2018 елда бирелгән һәм максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертларның калган өлешләренә ихтыяҗ булуы турындагы карарлар әлеге калдык өлештән артмаган күләмдә кабул ителә:

- финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып бюджетара трансфертларның калган өлеше булган Шәһәр бюджеты акчаларын алучы тарафыннан кабул ителгән бюджет йөкләмәләре үтәлмәгән очракта,

- әгәр файдаланылмаган бюджетара трансфертларны биргәндә элегрәк билгеләнгән тиешле максатларга туры килә торган максатларга 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Шәһәр бюджетына бюджетара трансфертларны бирү күздә тотылмаса һәм финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып бюджетара трансфертларның калган өлеше булган Шәһәр бюджеты акчаларын алучы тарафыннан кабул ителгән бюджет йөкләмәләре үтәлмәсә;

д) муниципаль казна һәм автоном учреждениеләр 2019 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына калган субсидияләрне кире кайтаруны тәэмин итә:

- муниципаль биремдә билгеләнгән, ирешелмәгән күрсәткечләргә туры килә торган күләмдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремнәр үтәлешен финанс яктан тәэмин итүгә 2018 елда үзләренә бирелгәннәрне. Шәһәр бюджеты керемнәренең баш администраторы күрсәтелгән калдыкларны муниципаль биремнәрнең үтәлеше турындагы хисаплар нигезендә кире кайтаруны контрольдә тота,

- Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә аларга карата 2019 елда шул ук максатларга юнәлдерү ихтыяҗының булуы турында расланмаганнарны;

е) социаль-мәдәни өлкә объектларын һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт милкеннән муниципаль милеккә тапшыру, агымдагы елда тапшырылган объектларның эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын каплау чыганагын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары нигезендә башкарыла.

4. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә:

- 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Шәһәр бюджетының җыелма бюджет язмасында билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турындагы хәбәрләрне бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә җиткерергә;

- 2018 елда муниципаль контрактларда күрсәтелгән шартларга туры китереп түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү турында муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләү өчен тотылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдык өлеше суммасы чикләрендә 2019 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга

юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турындагы тәкъдимнәрне 15 февральгә кадәр кертергә;

- сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) булганда муниципаль берәмлекләргә муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле тотыла торган субсидияләрне һәм бүтән трансфертларны күчерүне гамәлгә ашырырга:

- контрактта (шартнамәдә) билгеләнгән күләмдә аванс түләү өчен;
- башкарылган эшләрне, хезмәтләр күрсәтүне, товарлар белән тәэмин итүне раслаучы документлар булганда контракт (шартнамә) буенча башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә, китерелгән товарга түләү өчен.

5. Алабуга шәһәре Башкарма комитетына:

- 2019 елның 1 февраленә кадәр 2019 елда чыгымнар буенча Шәһәр бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актларның проектларын кертергә;

- бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль программаларын Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәр советының «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2018 елның 13 декабрендәге 176 номерлы карарына туры китерергә.

6. Муниципаль берәмлек заказчыларына, шул исәптән муниципаль казна учреждениеләренә 2018 елда муниципаль контрактлардагы шартларга туры китереп түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләү өчен тотылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдык өлешләре буенча мәгълүматларны 2019 елның 1 февраленә кадәр Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына җиткерергә.

7. 2020 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләр рөхсәт ителми дип билгеләргә:

- агымдагы финанс елында, Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләүләргә күчерелгән акчаларны түләүгә бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш, бүтән максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитларыннан файдалану буенча экономия хисабына хезмәт хакы буенча билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын арттыру;

- хезмәт хакы буенча бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш, бүтән максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын арттыру максатларында хезмәт өчен түләүләргә күчерелгән акчаларны түләүгә билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын киметү;

- Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча конкурста, аукционда катнашуга заявкаларны тәэмин итү сыйфатында сатуларда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акча суммалары, Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар үтәлешен тәэмин итү сыйфатында Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итүгә сатып алуларда катнашучылар тарафыннан кертелә торган акчалар Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре учреждениеләренең алар тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре территориаль бүлегендә ачтырылган шәхси счетларында учреждениеләрнең вакытлыча карамагына керә торган акчалар белән операцияләрне исәпкә алу өчен

исәпкә алына;

- муниципаль казна һәм автоном учреждениеләр бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет акчалары хисабына түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (муниципаль контрактлар) төзегәндә аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы:

а) шартнамә (контракт) суммасының 100 процентына кадәрге күләмдә, ләкин билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артык түгел, – басма матбугатларга язылу һәм аларны сатып алу турында, элемтә, кабель һәм спутник телевидениесе хезмәтләрен күрсәтү турында, ягулык-майлау материалларын, транспорт чараларын, юлламалар, авиация, тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында баруга билетлар, ашыгыч билгеләнешле медикаментлар (кеше гомере өчен хәтәр барлыкка килгән хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәмен күрсәтүне таләп итүче медикаментлар) сатып алуга, квалификация арттыру курсларында укыту турында, һөнәри яктан яңадан әзерлек узу турында, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка төр конференцияләрдә катнашу турында, проект документациясенә экспертиза уздыру турында, капиталь төзелеш, реконструкция яки техник яктан яңадан җиһазландыру объектларының смета хакын билгеләүнең дөреслегенә тикшерү уздыру турында шартнамәләр (контрактлар) буенча, транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү, мәгълүмат белән тәэмин итү, ташу хезмәтләре өчен түләү шартнамәләре буенча, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чараларын уздыруга шартнамәләр буенча, янгын сүндерү чараларын уздыру турында шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча;

б) шартнамә (контракт) суммасының 30 процентыннан артмаган, әмма бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитларыннан артмаган күләмдә, – калган шартнамәләр (контрактлар) буенча, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

в) Шәһәр бюджетыннан юридик затларга (муниципаль учреждениеләрдән тыш), шәхси эшкуарларга, шулай ук физик затлар – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне җитештерүчеләргә субсидияләр бирү 2019 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

8. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә:

- 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Шәһәр бюджетының җыелма бюджет язмасында билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турындагы хәбәрләрне Алабуга шәһәре Башкарма комитетына җиткерергә.

9. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

10. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тоту өчен үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче К.В. Мокшин